| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30. 01. 2019 с.Старое Дрожжаное № 40

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Җирләү һәм күмү эше турында"гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Җирләү һәм күмү эше турында"гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында" гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең " 2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" гы 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә расларга һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында" гы 2018 елның 30 гыйнварындагы 53 номерлы карарын 2019 елның 1 февраленнән көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны "Туган як" район газетасында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф.Җәлаловка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазифаларын башкаручы Д.А. Сатдинов

Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» гыйнвар 2019 ел № 40
карарына 1 нче кушымта

2019 елның 1 февраленнән Чүпрәле муниципаль районында
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү
бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3200,38 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,76 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,33 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Башкарма комитетның
Эшләр идарәчесе Д.Р.Сабирҗанова

Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
« 30 » гыйнвар 2019 ел № 40
карарына 2 нче кушымта

2019 елның 1 февраленнән Чүпрәле муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 338,05 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2862,35 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,32 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Башкарма комитетның
Эшләр идарәчесе Д.Р.Сабирҗанова